КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 июль г.Казань № 520

Һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга дәүләт ярдәме турында

Һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга премиаль түләүләр күләмнәре;

һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларны бүләкләү тәртибе.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Ворлдскиллс» стандартлары буенча халыкара һәм Россия чемпионатларында югары казанышлар өчен «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) хәрәкәте җиңүчеләренә, призерларына һәм экспертларына дәүләт ярдәме турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1092 нче;

«Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча милли һәм халыкара чемпионатлар җиңүчеләрен, призерларын һәм экспертларын бүләкләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 февраль, 123 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча милли һәм халыкара чемпионатлар

җиңүчеләрен, призерларын һәм экспертларын бүләкләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 февраль, 123 нче карары белән расланган «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча милли һәм халыкара чемпионатлар җиңүчеләрен, призерларын һәм экспертларын бүләкләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 20 сентябрь, 862 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 5 июль, 520 нче
карары белән расланды

Ёөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга премиаль түләүләр күләмнәре

| Ярышлар төре | Премия түләү күләме, сум (физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | I урын | II урын | III урын | профессионализм өчен медальон |
| «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионатының һәм Югары технологияләр чемпионатының йомгаклау (төбәкара) этабы, «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионатының финалы, Һөнәри осталык буенча бөтенроссия чемпионатының югары технологияләр чемпионаты финалы, «Абилимпикс» инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча илкүләм чемпионатның финалы һәм илкүләм дәрәҗәдәге һөнәри осталык буенча башка чемпионатлар | 172 414 | 143 679 | 114 943 | 34 483 |
| Һөнәри осталык буенча халыкара чемпионат | 344 828 | 287 357 | 229 886 | 57 472 |
| Һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты | 459 771 | 402 299 | 344 828 | 114 943 |

___

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 5 июль, 520 нче карары белән расланды

һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларны бүләкләү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы һөнәри осталык буенча җыелма командасы составына керүче һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларында) югары казанышлар өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга премия түләүләрен түләү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

җиңүчеләр - һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатларында (конкурсларда) катнашу йомгаклары буенча алтын медаль алган һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатларында (конкурсларда) катнашучылар;

призерлар - һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатларында (конкурсларда) катнашу йомгаклары буенча һөнәри осталык буенча көмеш, бронза медаль яисә профессионализм өчен медальон алган һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатларында (конкурсларда) катнашучылар;

экспертлар - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы җыелма командасы составына кертелгән һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатлары (конкурслары) җиңүчеләрен, призерларын әзерләүдә турыдан-туры катнашучы яисә әзерлек процессын координацияләү өчен җаваплы затлар.

3. Һөнәри осталык буенча илкүләм, халыкара һәм дөнья чемпионатларында (конкурсларда) югары казанышларга ирешкән өчен җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга премия түләүләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының _________ № _________ карары белән расланган күләмнәр нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән түләнә.

Җиңүче ике һәм аннан күбрәк экспертлар тарафыннан әзерләнгән очракта, мондый экспертларга премия түләү премия түләүләренең расланган күләмнәреннән тигез өлешләрдә гамәлгә ашырыла.

4. Җиңүчеләр, призерлар һәм экспертлар, илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатының рәсми тәмамлануы көненнән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына премиаль бүләкләү алу өчен түбәндәге документларны һәм белешмәләрне тапшыралар:

премия түләү турында гаризаны;

шәхесне таныклый торган документ күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен яисә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән исәпкә кую турында хәбәрнамә күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне һәм мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминләштерү системаларында индивидуаль (шәхсиләштрелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән индивидуаль шәхси счет номеры турында белешмәләр булган документның күчермәсен;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана торган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

премиаль бүләкләү бирү өчен банк реквизитлары ( Россия кредит оешмаларында җиңүчеләр, призерлар, экспертлар тарафыннан ачыдган шәхси счетларга акчалар күчерелгән очракта).

5. Илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионаты рәсми тәмамланган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән премиаль бүләкләүләр өчен җиңүчеләр, призерлар һәм экспертлар исемлеге раслана.

6. Җиңүчеләргә, призерларга һәм экспертларга премия түләүләрен түләү, Россия кредит оешмаларында җиңүчеләр, призерлар, экспертлар ачкан шәхси счетларга акча күчерү юлы белән илкүләм, халыкара яисә дөнья чемпионатының рәсми тәмамланган көненнән соң 45 көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.